СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

29.09.2023 Баулы шәһәре № 215

Баулы муниципаль районы Советының 2017 елның 15 декабрендәге 139 номерлы “Баулы муницbackground районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәне раслау турында” карарына үзгәрешләр кертү турында

““Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү турында” 2022 елның 5 декабрендәге 512-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының 2017 елның 15 декабрендәге 139 номерлы Баулы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә (2018 елның 31 августындагы 166 номерлы, 2019 елның 20 маендагы 210 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 276 номерлы, 2023 елның 14 апрелендәге 173 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнмәгән булса, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының арендага алынган муниципаль күчемсез милекне хосусыйлаштыруда катнашу үзенчәлекләре федераль закон белән билгеләнә.”;

3.2 пунктында “дәүләтнең” сүзләрен төшереп калдырырга;

5.15 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«-юридик затка түләү күләме һәм тәртибе, "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 пунктындагы  8.1 пунктчасына ярашлы, муниципаль мөлкәтне сатучы һәм (яки) милекче исеменнән хосусыйлаштырыла торган муниципаль мөлкәтне сатуны оештыру йөкләнгән функцияләрне башкара;

- әлеге Федераль закон һәм (яки) башка федераль законнарда каралган җәмәгать сервитуты һәм (яки) чикләүләр белән мондый мөлкәтне йөкләүне билгеләү турында мәгълүмат;

- конкурс шартлары, формасы һәм аның үтәлү сроклары.»;

5.19. пунктының җиденче абзацында «дәүләтнең» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.6. Аукционда катнашу өчен дәгъвачы задаток кертә:

Муниципаль милекне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 20 проценты 100 миллион сум һәм аннан да күбрәк тәшкил итә;

муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 10 проценты 100 миллион сумнан кимрәк тәшкил итә;

Мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән счетка задатокның килүен раслаучы документ булып, әлеге счеттан өземтә тора»;

6.13. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Акуцион нәтиҗәләре уздырылган датадан соң, биш эш көне эчендә, аукцион җиңүчесе яки аукционның бердән-бер катнашучысы дип танылган зат, әгәр дә аукционда катнашырга заявканы бер генә кеше биргән очракта, әлеге зат белән килешү муниципаль мөлкәтне сатуның беренчел бәясе буенча төзелә, сатып алу-сату килешүе төзелә. Муниципаль мөлкәт җәмәгать сервитуты белән йөкләнгән очракта һәм (яки) “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законында каралган һәм (яки) башка федераль законнар белән, акуционда төзелә торган мондый мөлкәтне сатып алу- сату килешүенең төп шарты булып, сатып алучының күрсәтелгән йөкләмә шартларын үтәү бурычы тора.

Аукцион уздыру нәтиҗәләре буенча билгеләнгән муниципаль мөлкәт бәясе, аукцион нәтиҗәләреннән аерым бәхәсләштерелергә тиеш түгел.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
Район Советы Рәисе И.И. Гозәеров